«гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү – табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы булганда яисә барлыкка килгәндә, шулай ук хәрби гамәлләр үткәрелгәндә яисә шушы гамәлләр аркасында барлыкка килә торган куркынычлар турында, халыкка үз-үзен тоту кагыйдәләре һәм саклану чаралары күрү зарурлыгы турында хәбәр итү сигналларын һәм экстрен мәгълүматны халыкка җиткерү;

гадәттән тыш хәлләр турында халыкка мәгълүмат бирү – фаразлана торган һәм барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр,

халыкның һәм территорияләрнең иминлеген тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар, саклану алымнары һәм ысуллары турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка каналлар буенча халыкка мәгълүмат җиткерү, шулай ук гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә белемнәрне пропагандалау;

гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яисә барлыкка килү турында халыкка экстрен хәбәр итүнең комплекслы системасы — гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү системасының хәбәр җиткерү һәм куркыныч табигый күренешләрне һәм техноген процессларны мониторинглау системаларының программа-техник чаралар комплексыннан торган, хәбәр итү сигналларын һәм экстрен мәгълүматны гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының идарә органнарына һәм халыкка автомат һәм (яисә) автоматлаштырылган режимнарда җиткерүне тәэмин итүче элементы;

халыкка экстрен хәбәр итү зонасы — шушы территориядә булган кешеләр тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыручы бик тиз таралучан куркыныч табигый күренешләр һәм техноген процесслар барлыкка килү куркынычы булган территория.»;

2) 9 статьяның беренче өлешендә:

а) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гадәттән тыш хәлләр турында халыкка мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыру;»;

б) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системаларын булдыру һәм даими әзерлек хәлендә тоту;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм мондый мәгълүматны алмашу, муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яисә барлыкка килү турында халыкка үз вакытында, шул исәптән гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яисә барлыкка килү турында халыкка экстрен хәбәр итүнең комплекслы системасын кулланып хәбәр итүне тәэмин итү;

вәкаләтләренә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау бурычларын хәл итү керә торган федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, шулай ук территорияләрендә гадәттән тыш хәл барлыкка килергә мөмкин булган җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән килештереп, халыкка экстрен хәбәр итү зоналарының чикләрен билгеләү.»;



3) 10 статьяда:

а) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм мондый мәгълүматны алмашу, гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яисә барлыкка килү турында халыкка үз вакытында, шул исәптән гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яисә барлыкка килү турында халыкка экстрен хәбәр итүнең комплекслы системасын кулланып хәбәр итүне тәэмин итү;»;

б) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гадәттән тыш хәлләр турында халыкка мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыру;»;

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирүнең муниципаль системаларын булдыру һәм даими әзерлек хәлендә тоту.»;

4) 16 статьяда:

а) икенче өлештә «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;

б) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре һәм аларның башка хезмәткәрләре гадәттән тыш хәлләрдәге гамәлләргә әзерлекне белем бирү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче оешмаларда һәм турыдан-туры эш урыннарында узалар.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 7 марты
№ 15-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 206. Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 13 февралендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон җәмәгать тәртибен, йорт хайваннарының тискәре йогынтысыннан кешеләрне яклауны, йорт хайваннарына карата рәхимсезлек кылуны булдырмауны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның гомуми принципларын һәм төп кагыйдәләрен, шулай ук йорт хайваннарының аерым төрләрен тоту үзенчәлекләрен билгели.

2. Авыл хуҗалыгы терлеген, фәнни оешмаларының фәнни тикшеренүләре объектлары булып торучы, хезмәт яисә коммерция максатларында кулланыла торган йорт хайваннарын, шулай ук читлектәге кыргый хайваннарны тоту өлкәсендәге мөнәсәбәтләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән, шулай ук алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән җайга салына.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) йорт хайваны – физик яисә юридик затлар каравындагы хайван;

2) йорт хайванын тоту – йорт хайванының гомерен һәм сәламәтлеген саклап калу, йорт хайванының сәламәт токымын алу өчен, шулай ук җәмәгать тәртибен, кешеләрнең һәм хайваннарның иминлеген тәэмин итү өчен йорт хайваны хуҗасы тарафыннан күрелә торган чаралар;

3) йорт хайваннарына карата рәхимсезлек кылу – йорт хайванының имгәнүенә, җәрәхәтләнүенә, авыруына яисә үлеменә китергән белә торып кылган гамәл яисә гамәл кылмау;

4) йорт хайванын урамда йөртү – йорт хайванын аны тоту урыны булып тора торган урыннан яисә җир кишәрлегеннән читкә алып чыгу;



5) хайваннар өчен приют – күзәтүчесез хайваннарны, шулай ук хуҗалары карый алмаган йорт хайваннарын тоту өчен билгеләнгән урын;

6) күзәтүчесез хайваннарны вакытлыча тоту пункты – күзәтүчесез хайваннарны тикшерү, мәҗбүри профилактик ветеринар чаралар үткәрү, стерильләштерү (кастрацияләү) максатларында вакытлыча тоту өчен билгеләнгән урын;

7) этне теркәү турында таныклык – этне теркәгәндә бирелә торган документ, ул эт һәм аның хуҗасы турындагы мәгълүматны үз эченә ала;

8) этнең идентификация номеры – этне теркәгәндә аңа бирелә торган номер;

9) кечкенә эт – җилкә калкымыннан буе 30 сантиметрдан ким булган эт.

3 статья. **Йорт хайваннарын тотуның төп принциплары**

Йорт хайваннарын тоту түбәндәге төп принципларга нигезләнә:

1) йорт хайваннарына карата кешелекле мөнәсәбәт;

2) санитария-эпидемиология һәм ветеринария кагыйдәләрен үтәү;

3) халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән һәм йорт хайваннарының тискәре йогынтысыннан яклау;

4) йорт хайваннарын яклау гамәлләрен башкаруда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының катнашуы;

5) йорт хайваннарын тоту өлкәсендәге законнарны бозган өчен җаваплылык.

4 статья. **Йорт хайваннарын тоту өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Йорт хайваннарын тоту өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) күзәтүчесез хайваннарны, шул исәптән югалган йорт хайваннарын аулау, тоту һәм исәбен җайга салу, шулай ук югалган йорт хайваннарының хуҗаларын эзләү буенча чаралар күрү;

2) этне теркәү турында таныклыкның формасын билгеләү;

3) потенциаль куркыныч эт токымнарының исемлеген билгеләү;

4) тиешле территориядә әлеге Законда каралган тәртиптә теркәлгән этләрнең саныннан чыгып, муниципаль берәмлектә этләрне урамда йөртү өчен урыннар булдыру зарурлыгын ачыклау критерийларын (нормаларын) билгеләү;

5) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә йорт хайваннарын тоту өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә Татарстан Республикасының ул вәкаләт биргән башкарма хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Йорт хайваннарын тоту өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре чикләрендә:

1) этләрне урамда йөртү өчен урыннар билгелиләр һәм җиһазлыйлар;

2) югалган йорт хайваннарының хуҗаларын эзләү буенча чаралар күрәләр;

3) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә йорт хайваннарын тоту өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

2. Йорт хайваннарын тоту өлкәсендәге аерым дәүләт вәкаләтләре җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән вәкаләтләр бирелгән очракта гамәлгә ашырыла.

6 статья. **Йорт хайваннарын тоту шартлары**

1. Йорт хайваннарын тоту урыннары йорт хайваннарының индивидуаль, шул исәптән пространствога, температурага, яктылыкка һәм җилләтелүгә кагылышлы ихтыяҗларын исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

2. Йорт хайванын җир кишәрлегендә тотканда, аның өчен әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган, аны тоту өчен җайлаштырылган урын корылган булырга тиеш.

3. Йорт хайванын торак урында тотканда аның хуҗасы шушы торак урында яшәүче гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга, санитария-эпидемиология һәм ветеринария кагыйдәләрен, шулай ук торак урыннардан файдалану кагыйдәләрен үтәргә тиеш.

4. Йорт хайванын берничә гаилә яши торган торак урында тоту күрсәтелгән гаиләләрнең барлык балигъ әгъзаларының язма ризалыгы булганда гына рөхсәт ителә. Күпфатирлы йорттагы торак урында потенциаль куркыныч токымлы этне тоту өчен шулай ук потенциаль куркыныч токымлы этне тоту планлаштырылган торак урын белән бер подъездда урнашкан торак урыннарда яшәүче күпчелек балигъ гражданнарның язма ризалыгын алу таләп ителә. Әлеге өлештә күрсәтелгән таләпләр торак урыннарда сукырларны йөртүче этләрне тоту очракларына кагылмый.

5. Җир кишәрлегендә тотылучы эт тирә-яктагыларның куркынычсызлыгын тәэмин итә торган бәйдә яисә вольерда булырга тиеш. Җир кишәрлеге эт аның чикләреннән мөстәкыйль рәвештә чыга алмаслык алым белән киртәләнгән очракта, этне җир кишәрлегендә бәйдән башка һәм вольердан читтә тоту рөхсәт ителә. Җир кишәрлеге территориясенә керү урынында җир кишәрлегендә эт булу турында кисәтү язуы урнаштырылган булырга тиеш.

7 статья. **Йорт хайваннары хуҗаларының бурычлары**

1. Йорт хайваннарының хуҗалары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) йорт хайванына карата рәхимсезлек кылуга юл куймаска;

2) йорт хайванын карауны аның табигый, шул исәптән тулы рационлы азыкка, суга, йокыга, физик нагрузкага ихтыяҗларын исәпкә алып башкарырга;

3) йорт хайванына ветеринария ярдәмен күрсәтүне һәм йорт хайванына карата мәҗбүри профилактик ветеринария чараларын үткәрүне үз вакытында тәэмин итәргә;

4) вакытлыча изоляцияләүне, контрацептив чараларны, стерильләштерүне (кастрацияләүне) куллану юлы белән йорт хайванының кирәкмәгән үрчемен булдырмау чараларын күрергә;

5) тынлыкны һәм гражданнар тынычлыгын бозмаска, йорт хайванын тотканда аларның куркынычсызлыгын тәэмин итәргә;

6) йорт хайванының башка хайваннарны яисә кешеләрне тешләү очраклары турында тешләү вакытыннан алып бер көн эчендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органына яисә аның буйсынуындагы учреждениеләргә хәбәр итәргә һәм йорт хайванын тикшерү өчен бирергә;

7) хуҗаның рәттән ике көннән артык йорт хайванын карап тору мөмкинлеге булмаса, йорт хайванын, тоту өчен, хайваннар өчен приютка урнаштырырга яисә аны, тоту өчен, башка затларга бирергә;

8) гомуми файдаланудагы урыннарны һәм территорияләрне йорт хайваннары тарафыннан пычратуга юл куймаска;

9) йорт хайваннарын урамда йөрткәндә, аларның табигый ихтыяҗ калдыкларын җыярга;

10) әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән этне, тоту өчен, башка затка тапшырганда, этне теркәү турындагы таныклыкны бирергә;

11) йорт хайванына милек хокукыннан яисә башка хокуктан баш тарткан очракта, аңа яңа хуҗа табарга яисә аны күзәтүчесез хайваннарны вакытлыча тоту пунктына тапшырырга;

12) йорт хайваны үлгән очракта, биологик калдыкларны җыюны, утильләштерүне һәм юк итүне башкаруны җайга сала торган Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә аны утильләштерүне тәэмин итәргә;

13) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә йорт хайваннарын тоту буенча башка таләпләрне үтәргә.

2. Йорт хайваннары хуҗаларына түбәндәгеләр тыела:

1) йорт хайванының имгәнүенә, җәрәхәтләнүенә, авыруына яисә үлүенә китерә торган инвентарь һәм башка җайланмалар куллану;

2) йорт хайванын башка хайваннарга яисә кешеләргә өстерү;

3) йорт хайванын өйрәтүнең (дрессировкалауның) кешелексез алымнарын куллану;

4) йорт хайваннары катнашында сугышлар оештыру һәм үткәрү.

8 статья. **Этләрне теркәү**

1. Татарстан Республикасы территориясендә этләрне исәпләү, кеше һәм хайваннар өчен уртак авырулар килеп чыгуны кисәтү, югалган этләрне эзләү һәм аларны хуҗаларына кайтару максатларында Татарстан Республикасында этләрне теркәү алар турында хәбәр ителгәннән соң гамәлгә ашырыла.

2. Этне теркәү өчен аның хуҗасы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең этләрне теркәүгә вәкаләтле органына (алга таба – вәкаләтле орган) гариза белән мөрәҗәгать итә һәм этен тикшерү өчен бирә. Этне теркәгәндә аның хуҗасына этне теркәү турында таныклык бирелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) этнең теркәгәндә бирелә торган идентификация номеры;

2) эт хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт белешмәләре, аның булу урыны буенча яисә яшәү урыны буенча теркәлүе турында, шулай ук фактта яшәү урыны хакында (әгәр хуҗасы физик зат булса) белешмәләр;

3) юридик затның атамасы һәм урнашу урыны (әгәр хуҗасы юридик зат булса);



4) этнең токымы, җенесе, төсе, исеме, аерым билгеләре, этнең электрон мәгълүмат чыганагы (микрочибы) булу турында белешмәләр;

5) эткә карата үткәрелгән мәҗбүри профилактик ветеринария чаралары турында мәгълүмат;

6) эт тотылачак урынның яисә җир кишәрлегенең адресы.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр үзгәргән очракта, эт хуҗасы 14 көн эчендә этне теркәү турындагы таныклыкка тиешле үзгәрешләр кертү хакында гариза белән вәкаләтле органга мөрәҗәгать итәргә тиеш.

4. Этне теркәү, этне теркәү турындагы таныклыкка үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла. Этне теркәү, этне теркәү турындагы таныклыкка үзгәрешләр кертү өчен түләү алынмый. Этне теркәгән вакытта ветеринария хезмәтләре күрсәтелсә, аларны күрсәткән өчен түләү алына, аның күләме Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

5. Эт үлгән яисә ул күзәтүчесез хайваннарны вакытлыча тоту пунктына тапшырылган очракта, этне теркәү исәбеннән чыгару аның хуҗасы гаризасы буенча гамәлгә ашырыла.

9 статья. **Этләрне урамда йөртү кагыйдәләре**

1. Этне урамда йөртүче зат, әйләнә-тирәдәгеләрнең иминлеген тәэмин итү максатларында, этнең хәрәкәтләрен контрольдә тотарга һәм урамда йөргәндә агрессив тәртибен булдырмаска тиеш.

2. Этне урамда йөртү, өч айга кадәрге көчекләрне һәм махсус сумкага (контейнерга) салынган яисә урамда йөртүче кулында булган кечкенә этләрне урамда йөртү очракларыннан тыш, бау (этне тотып тора торган башка җайланма), муенчак һәм борынчак кулланып башкарыла. Әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән этнең муенчагында аның идентификация номеры күрсәтелгән булырга тиеш. Этне урамда баусыз йөртү торак пунктлар чикләреннән читтә, шулай ук урамда болай йөртүне рөхсәт итә торган билгеләр урнаштырылган урыннарда рөхсәт ителә.

3. Түбәндәгеләр тыела:

1) этләрне балалар һәм спорт мәйданчыкларында, пляжларда, мәгариф һәм медицина оешмалары территорияләрендә урамда йөртү;

2) этләрне гражданнарның күпләп ял итү урыннарында урнашкан су объектларында коендыру;

3) әлеге Закон белән билгеләнгән тәртиптә теркәлмәгән этләрне җәмәгать урыннарында аларның табигый ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында урамда йөртү;

4) этләрне урамда йөрткәндә аларны караусыз калдыру;

5) алкогольле, наркотик яисә токсик исерү халәтендәге затларга, шулай ук яше һәм сәламәтлек торышы буенча этләренең хәрәкәтләрен контрольдә тота алмаган һәм урамда йөргәндә агрессив тәртибен булдырмый кала алмаган затларга этләрне урамда йөртү;

6) 14 яшькә җитмәгән затларга, кечкенә этләрне урамда йөртү очракларыннан тыш, этләрне урамда йөртү.

10 статья. **Йорт хайваннарын юк итү**

1. Йорт хайваннарын түбәндәге очракларда юк итү рөхсәт ителә:

1) йорт хайваннарында аеруча куркыныч хайван авырулары табылган очракта;

2) артык агрессив йорт хайваннарын;

3) һөҗүм итүче йорт хайваны кешеләрнең гомере яисә сәламәтлеге өчен куркыныч тудырса, әлеге хайваннан сакланган вакытта;

4) законнарда каралган башка очракларда.

2. Йорт хайваннарын юк итү, әлеге статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында каралган очраклардан тыш, балигъ булмаганнар катнашында рөхсәт ителми һәм, тиз һәм авыртуларсыз үлемне гарантияли торган алымнар кулланып, ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан башкарылырга тиеш.

11 статья. **Йорт хайваннарын тоту өлкәсендә законнарны бозган өчен җаваплылык**

Йорт хайваннарын тоту өлкәсендә законнарны бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

12 статья. **Күчмә нигезләмәләр**

Әлеге Законның 6 статьясындагы 4 өлеше таләпләре 2015 елның 1 гыйнварына кадәр әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән этләрне күпфатирлы йортларда торак урыннарында тоту очракларына кагылмый.



13 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 60 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актларны әлеге Закон үз көченә кергән көннән дә соңга калмыйча кабул итәргә тиеш.

3. Әлеге Законның 6 статьясындагы 4 өлеше, 9 статьясындагы 3 өлешенең 3 пункты 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге статьяның 2 өлеше шушы Закон рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 7 марты
№ 16-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 207. Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 13 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 3 пунктына «, шулай ук аквакультура (балыкчылык) максатлары өчен» сүзләрен өстәргә;

2) $33^1$ статьяның 1 пунктындагы өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 40 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Ясалма сугарыла торган авыл хуҗалыгы җирләре һәм (яисә) киптерелә торган җирләр өчен җир кишәрлегенең минималь күләме Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең агросәнәгать комплексы белән идарә итү өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.»;

4) түбәндәге эчтәлекле $40^1$ статья өстәргә:

«$40^1$ статья. **Татарстан Республикасы территориясендәге аеруча әһәмиятле продуктив авыл хуҗалыгы җирләре**

1. Татарстан Республикасы территориясендәге башка максатларда файдалану рөхсәт ителми торган аеруча әһәмиятле продуктив авыл хуҗалыгы җирләренә, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, түбәндәгеләр керә:

1) фәнни оешмаларның тәҗрибә-житештерү бүлекчәләренең һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының уку-тәҗрибә бүлекчәләренең авыл хуҗалыгы җирләре;

2) муниципаль район (шәһәр округы) буенча кадастр бәясе аның уртача дәрәҗәсенең 50 процентыннан һәм аннан да артыграк булган авыл хуҗалыгы җирләре;

3) селекция казанышлары сынауларын башкару, саклау һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән авыл хуҗалыгы җирләре;

4) ясалма рәвештә сугарыла торган авыл хуҗалыгы җирләре һәм стационар сугару системалары, ябык киптерү системалары булган киптерелә торган җирләр.

2. Татарстан Республикасы территориясендәге башка максатларда файдалану рөхсәт ителми торган аеруча әһәмиятле продуктив авыл хуҗалыгы җирләре исемлеге (алга таба – Исемлек) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең агросәнәгать комплексы белән идарә итү өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан төзелә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3. Исемлеккә кертелгән җир кишәрлекләре турында мәгълүмат «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең агросәнәгать комплексы белән идарә итү өлкәсендәге вәкаләтле органының рәсми сайтында урнаштырыла.»;



5) 44 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы милкендәге яисә муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, өч елдан алып кырык тугыз елга кадәр срокка төзелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 7 марты
№ 17-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 208. «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 94-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяда:

а) беренче абзацта «12 180 399,8» саннарын «10 613 230,2» саннарына, «10 516 738,1» саннарын «9 032 727,9» саннарына, «9 374 856,1» саннарын «8 001 725,1» саннарына алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджет-

ларына субсидияләр 2014 елга 1 458 477,7 мең сум, 2015 елга 509 341,8 мең сум һәм 2016 елга 261 893,5 мең сум күләмендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә бүлеп;»;

2) 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына
5 нче кушымта

**2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр бүлү нормативлары**

(процентларда)

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | шәһәр һәм авыл җирлекләре | |
| 1 05 00000 00 0000 110 | Җыелма керемгә салымнар | | | | | |
| 1 05 03020 01 0000 110 | Бердәй авыл хуҗалыгы салымы (2011 елның 1 гыйнварына тәмамланган салым чорлары өчен) | | 90 | 60 | 30 | |
| 1 09 00000 00 0000 000 | Юкка чыгарылган салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурыч һәм яңадан исәпләүләр | | | | | |
| 1 09 04010 02 0000 110 | Предприятиеләр мөлкәтенә салым | 100 | | | | |
| 1 09 06010 02 0000 110 | Сатулардан салым | 100 | | | | |



| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | шәһәр һәм авыл җирлекләре | |
| 1 09 06020 02 0000 110 | Мәгариф учреждениеләре ихтыяҗларына юридик затлардан алына торган җыем | 100 | | | | |
| 1 09 06030 02 0000 110 | Башка салымнар һәм җыемнар <*> | 100 | | | | |
| 1 09 07012 04 0000 110 | Шәһәр округлары территорияләрендә туплана торган реклама салымы | | 100 | | | |
| 1 09 07013 05 0000 110 | Муниципаль районнар территорияләрендә туплана торган реклама салымы | | | 100 | | |
| 1 09 07032 04 0000 110 | Гражданнардан һәм предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, оешмалардан полицияне тотуга, территорияләрне төзекләндерүгә, мәгариф һәм башка максатларга шәһәр округлары территорияләрендә туплана торган максатчан җыемнар | | 100 | | | |
| 1 09 07033 05 0000 110 | Гражданнардан һәм предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, оешмалардан милицияне тотуга, территорияләрне төзекләндерүгә, мәгариф һәм башка максатларга муниципаль районнар территорияләрендә туплана торган максатчан җыемнар | | | 100 | | |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | шәһәр һәм авыл җирлекләре | |
| 1 09 07052 04 0000 110 | Шәһәр округлары территорияләрендә туплана торган башка җирле салымнар һәм җыемнар | | 100 | | | |
| 1 09 07053 05 0000 110 | Муниципаль районнар территорияләрендә туплана торган башка җирле салымнар һәм җыемнар | | | 100 | | |
| 1 09 11010 02 0000 110 | Салым салуның гадиләштерелгән системасы куллануга бәйле патент хакы рәвешендә алына торган салым | | 100 | 100 | | |
| 1 09 11020 02 0000 110 | Салым салуның гадиләштерелгән системасы куллануга бәйле патент хакы рәвешендә алына торган салымнар (2011 елның 1 гыйнварына тәмамланган салым чорлары өчен) | | 90 | 90 | | |
| 1 13 00000 00 0000 000 | Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | | | | | |
| 1 13 01994 04 0000 130 | Шәһәр округлары бюджетлары акчаларын алучыларның түләүле хезмәт күрсәтүләрдән (эшләрдән) башка керемнәре | | 100 | | | |



| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | шәһәр һәм авыл җирлекләре | |
| 1 13 01995 05 0000 130 | Муниципаль районнар бюджетлары акчаларын алучыларның түләүле хезмәт күрсәтүләрдән (эшләрдән) башка керемнәре | | | 100 | | |
| 1 13 01995 10 0000 130 | Җирлекләр бюджетлары акчаларын алучыларның түләүле хезмәт күрсәтүләрдән (эшләрдән) башка керемнәре | | | | 100 | |
| 1 13 02064 04 0000 130 | Шәһәр округлары мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле тотылган чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган керемнәр | | 100 | | | |
| 1 13 02065 05 0000 130 | Муниципаль районнар мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле тотылган чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган керемнәр | | | 100 | | |
| 1 13 02065 10 0000 130 | Җирлекләр мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле тотылган чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган керемнәр | | | | 100 | |
| 1 13 02992 02 0001 130 | Үткән еллардагы дебитор бурычын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | 100 | | | | |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | шәһәр һәм авыл җирлекләре | |
| 1 13 02992 02 0002 130 | Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | 100 | | | | |
| 1 13 02994 04 0000 130 | Шәһәр округлары бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | | 100 | | | |
| 1 13 02995 05 0000 130 | Муниципаль районнар бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | | | 100 | | |
| 1 13 02995 10 0000 130 | Җирлекләр бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | | | | 100 | |
| 1 15 00000 00 0000 000 | Административ түләүләр һәм җыемнар | | | | | |
| 1 15 02040 04 0000 140 | Аерым функцияләрне башкарган өчен шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (оешмалар) тарафыннан алына торган түләүләр | | 100 | | | |
| 1 15 02050 05 0000 140 | Аерым функцияләрне башкарган өчен муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары (оешмалар) тарафыннан алына торган түләүләр | | | 100 | | |
| 1 15 02050 10 0000 140 | Аерым функцияләрне башкарган өчен җирлекләрнең җирле үзидарә органнары (оешмалар) тарафыннан алына торган түләүләр | | | | 100 | |



| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | шәһәр һәм авыл җирлекләре | |
| 1 16 00000 00 0000 000 | Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | | | | | |
| 1 16 90020 02 0001 140 | Акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм зыянны каплауга бүтән суммалардан Татарстан Республикасы бюджетына кертелә торган бүтән кертемнәр | 100 | | | | |
| 1 16 90020 02 0003 140 | Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контракты шартларын бозган өчен акчалата түләтүләр (неустойка) | 100 | | | | |
| 1 16 90020 02 0004 140 | Дәүләт заказлары буенча претензия һәм дәгъва эше нәтиҗәсендә акчалата түләтүләр | 100 | | | | |
| 1 17 00000 00 0000 000 | Салым булмаган башка керемнәр | | | | | |
| 1 17 01040 04 0000 180 | Шәһәр округлары бюджетларына кертелә торган ачыкланмаган кертемнәр | | 100 | | | |
| 1 17 01050 05 0000 180 | Муниципаль районнар бюджетларына кертелә торган ачыкланмаган кертемнәр | | | 100 | | |
| 1 17 01050 10 0000 180 | Җирлекләр бюджетларына кертелә торган ачыкланмаган кертемнәр | | | | 100 | |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | шәһәр һәм авыл җирлекләре | |
| 1 17 01090 09 0000 180 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетларына кертелә торган ачыкланмаган кертемнәр | | | | | 100 |
| 1 17 02010 04 0000 180 | Шәһәр округлары территорияләрендә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләрен тартып алуга бәйле рәвештә авыл хуҗалыгы җитештерүе югалтуларын каплау (2008 елның 1 гыйнварына барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) | | 100 | | | |
| 1 17 02020 05 0000 180 | Авыл арасындагы территорияләрдә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләрен тартып алуга бәйле рәвештә авыл хуҗалыгы җитештерүе югалтуларын каплау (2008 елның 1 гыйнварына барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) | | | 100 | | |
| 1 17 02020 10 0000 180 | Җирлекләр территорияләрендә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләрен тартып алуга бәйле рәвештә авыл хуҗалыгы җитештерүе югалтуларын каплау (2008 елның 1 гыйнварына барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) | | | | 100 | |



| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | шәһәр һәм авыл җирлекләре | |
| 1 17 05020 02 0001 180 | Татарстан Республикасы бюджетының салым булмаган башка керемнәре | 100 | | | | |
| 1 17 05020 02 0002 180 | Гражданнарга Татарстан Республикасы алдындагы аерым казанышлар өчен дәүләт пенсияләренә өстәмә түләүгә оешмалардан керемнәр | 100 | | | | |
| 1 17 05040 04 0000 180 | Шәһәр округлары бюджетларыннан салым булмаган башка керемнәр | | 100 | | | |
| 1 17 05050 05 0000 180 | Муниципаль районнар бюджетларыннан салым булмаган башка керемнәр | | | 100 | | |
| 1 17 05050 10 0000 180 | Җирлекләр бюджетларыннан салым булмаган башка керемнәр | | | | 100 | |
| 1 17 14020 04 0000 180 | Шәһәр округлары бюджетларына гражданнарның үзләре күчерә торган салым акчалары | | 100 | | | |
| 1 17 14030 05 0000 180 | Муниципаль районнар бюджетларына гражданнарның үзләре күчерә торган салым акчалары | | | 100 | | |
| 1 17 14030 10 0000 180 | Җирлекләр бюджетларына гражданнарның үзләре күчерә торган салым акчалары | | | | 100 | |

--------------------------------

<*> – юкка чыгарылган региональ салымнар һәм җыемнар өлешендә»;

3) 6 нчы кушымтада:

а)

«701 1 12 05020 02 0000 120 Россия Федерациясе субъектлары милкендәге су объектларыннан файдаланган өчен түләү»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«701 1 16 25086 02 0000 140 Федераль милектәге су объектларында су законнарын бозган өчен билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан салына торган акчалата түләүләр (штрафлар)»;

б)

«754 1 12 04080 02 0000 120 Россия Федерациясе урман фондыннан һәм башка категорияләрдәге урманнардан файдаланудан бүтән керемнәр (2007 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән йөкләмәләр буенча)»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«754 1 13 01410 01 0000 130 Россия Федерациясе субъектлары дәүләт органнары, Россия Федерациясе субъектлары казна учреждениеләре тарафыннан әлеге дәүләт органнарының, учреждениеләренең дәүләт реестрлары (регистрлары) документларындагы белешмәләрне биргән өчен түләү»;

в)

«000 1 13 02992 02 0002 130 Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«000 1 14 02022 02 0000 440 Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары карамагындагы учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне сатудан керемнәр (Россия Федерациясе субъектларының бюджет һәм автоном учреждениеләре мөлкәтеннән тыш), күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны сату өлешендә»;

г)

«000 2 02 02208 02 0000 151 «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр»



юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«000 2 02 02217 02 0000 151 Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә региональ проектларга ярдәмгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр»;

д)

«000 2 02 03122 02 0000 151 Вакытлыча хезмәткә сәләтсез булу очрагында һәм бала табуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган затларга һәм оешма бетүгә (физик затлар тарафыннан эшчәнлек туктатылуга, вәкаләтләр бетүгә) бәйле рәвештә эшләреннән азат ителгән затларга дәүләт пособиеләре түләүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субвенцияләр»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«000 2 02 03998 02 0000 151 Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бердәй субвенция»;

4) 8 нче кушымтаның 1 нче таблицасында:

а)

| | | |
|---|---|---|
| «Гомумдәүләт мәсьәләләре | 01 | 15 511 345,4» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Гомумдәүләт мәсьәләләре | 01 | 14 898 277,9»; |

б)

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 01 | 13 | 11 489 635,3» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 01 | 13 | 10 876 567,8»; |

в)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Халыкара хезмәттәшлек | 01 | 13 | 0300000 | | 2 827,2 |
| Дәүләтнең башка йөкләмәләрен үтәү | 01 | 13 | 0300600 | | 2 827,2 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү | 01 | 13 | 0300600 | 200 | 2 827,2» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Халыкара хезмәттәшлек | 01 | 13 | 0300000 | | 3 227,7 |
| Дәүләтнең башка йөкләмәләрен үтәү | 01 | 13 | 0300600 | | 3 227,7 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү | 01 | 13 | 0300600 | 200 | 3 227,7»; |

г)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Гомумдәүләт идарәсенә бәйле дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру | 01 | 13 | 0920000 | | 9 498 226,2 |
| Дәүләтнең башка йөкләмәләрен үтәү | 01 | 13 | 0920300 | | 7 154 499,0 |
| Дәүләт йөкләмәләре буенча башка түләүләр | 01 | 13 | 0920305 | | 3 142 894,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү | 01 | 13 | 0920305 | 200 | 11 825,1» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Гомумдәүләт идарәсенә бәйле дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру | 01 | 13 | 0920000 | | 9 304 182,7 |
| Дәүләтнең башка йөкләмәләрен үтәү | 01 | 13 | 0920300 | | 6 965 290,8 |
| Дәүләт йөкләмәләре буенча башка түләүләр | 01 | 13 | 0920305 | | 3 151 704,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү | 01 | 13 | 0920305 | 200 | 20 635,1»; |

д)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы территориясендә федераль максатчан программаларны финанслашу | 01 | 13 | 0920306 | | 2 013 600,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 01 | 13 | 0920306 | 800 | 2 013 600,0» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы территориясендә федераль максатчан программаларны финанслашу | 01 | 13 | 0920306 | | 1 815 581,8 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 01 | 13 | 0920306 | 800 | 1 815 581,8»; |



е)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү | 01 | 13 | 0929900 | | 19 483,8 |
| Учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү | 01 | 13 | 0929902 | | 19 483,8 |
| Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 01 | 13 | 0929902 | 600 | 19 483,8» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү | 01 | 13 | 0929900 | | 14 648,5 |
| Учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү | 01 | 13 | 0929902 | | 14 648,5 |
| Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 01 | 13 | 0929902 | 600 | 14 648,5»; |

ж)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады» дәүләт программасы | 01 | 13 | 1100000 | | 183 924,9 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы | 01 | 13 | 1110000 | | 183 924,9» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады» дәүләт программасы | 01 | 13 | 1100000 | | 177 279,3 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы | 01 | 13 | 1110000 | | 177 279,3»; |

з)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Гомумдәүләт идарәсенә бәйле дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру | 01 | 13 | 1119200 | | 57 107,5» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Гомумдәүләт идарәсенә бәйле дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру | 01 | 13 | 1119200 | | 50 461,9»; |

и)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү | 01 | 13 | 1119299 | | 7 694,4 |
| Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 01 | 13 | 1119299 | 600 | 7 694,4» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү | 01 | 13 | 1119299 | | 1 048,8 |
| Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 01 | 13 | 1119299 | 600 | 1 048,8»; |

к)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 01 | 13 | 2412330 | 600 | 6 862,1» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» дәүләт программасы | 01 | 13 | 2500000 | | 11 480,9 |
| Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 01 | 13 | 2500000 | 600 | 11 480,9»; |

л)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Башка бюджет ассигнованиеләре | 01 | 13 | 4400002 | 800 | 1 969,0» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Социаль сәясәт өлкәсендә дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру | 01 | 13 | 5140000 | | 530,0 |
| 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарын социаль яклау» дәүләт программасының 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру | 01 | 13 | 5146027 | | 530,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү | 01 | 13 | 5146027 | 200 | 530,0»; |



м)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү, капиталь ремонтлау | 01 | 13 | 5230000 | | 749 288,8 |
| Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү, капиталь ремонтлау | 01 | 13 | 5231100 | | 749 288,8 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 01 | 13 | 5231100 | 800 | 749 288,8» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү, капиталь ремонтлау | 01 | 13 | 5230000 | | 324 499,0 |
| Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү, капиталь ремонтлау | 01 | 13 | 5231100 | | 112 201,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 01 | 13 | 5231100 | 800 | 112 201,0» |

һәм алардан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасын капиталь ремонтлау | 01 | 13 | 5233100 | | 140 968,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү | 01 | 13 | 5233100 | 200 | 140 968,0 |
| Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү | 01 | 13 | 5235100 | | 71 330,0 |
| Дәүләт (муниципаль) милкендәге күчемсез мөлкәт объектларына капитал салулар | 01 | 13 | 5235100 | 400 | 68 830,0 |
| Бюджетара трансфертлар | 01 | 13 | 5235100 | 500 | 2 500,0»; |

н)

| | | |
|---|---|---|
| «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге | 03 | 809 468,9» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге | 03 | 822 287,9»; |

о)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | 03 | 10 | | | 460 713,2» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | 03 | 10 | | | 473 532,2»; |

п)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү | 03 | 10 | 2027204 | 200 | 7 473,9» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү, капиталь ремонтлау | 03 | 10 | 5230000 | | 12 819,0 |
| Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү | 03 | 10 | 5235100 | | 12 819,0 |
| Дәүләт (муниципаль) милкендәге күчемсез мөлкәт объектларына капитал салулар | 03 | 10 | 5235100 | 400 | 12 819,0»; |

р)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Милли икътисад | 04 | | | | 27 698 739,7» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Милли икътисад | 04 | | | | 29 791 866,0»; |

с)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү | 04 | 04 | 2500000 | | 50 000,0» |

юлын төшереп калдырырга;

т)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Авыл хуҗалыгы һәм балыкчылык | 04 | 05 | | | 6 057 534,3» |



юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Авыл хуҗалыгы һәм балыкчылык | 04 | 05 | | | 5 958 834,3»; |

у)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү, капиталь ремонтлау | 04 | 05 | 5230000 | | 148 700,0» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү, капиталь ремонтлау | 04 | 05 | 5230000 | | 50 000,0»; |

ф)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү | 04 | 05 | 5235100 | | 98 700,0 |
| Дәүләт (муниципаль) милкендәге күчемсез мөлкәт объектларына капитал салулар | 04 | 05 | 5235100 | 400 | 98 700,0» |

юлларын төшереп калдырырга;

х)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Урман хуҗалыгы | 04 | 07 | | | 660 214,8» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Урман хуҗалыгы | 04 | 07 | | | 699 014,8»; |

ц)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасы | 04 | 07 | 1500000 | | 658 311,5» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасы | 04 | 07 | 1500000 | | 697 111,5»; |

ч)

| | | | | | |
| | |
|---|---|
| Васильев Валерий Павлович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты рәисе |
| Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |



45) «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге:

| | |
|---|---|
| Галиев Марат Һади улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе |
| Фәхретдинов Булат Альберт улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе. |

2. Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2010 елның 23 сентябрендәге 1127-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9);

2) «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2010 елның 23 сентябрендәге 1127-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 30 октябрендәге 2478-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 10 (II өлеш);

3) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 24 декабрендәге 2624-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 4 пункты (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (III өлеш);

4) «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2010 елның 23 сентябрендәге 1127-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 26 декабрендәге 3307-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 12 (II өлеш).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3434-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 241. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2013 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы доклады хакында

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2013 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы докладын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Т.Д. Нагумановның 2013 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы докладын игътибарга алырга (төп нөсхәгә кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасының кызыксынган министрлыклары һәм ведомстволары белән берлектә «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне карарга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белән берлектә кече һәм урта бизнес өлкәсендә законнарны камилләштерү буенча, шул исәптән эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларына гарантияләрне тәэмин итү, административ каршылыкларны киметү өлешендә, эшне дәвам итәргә тиеш.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2013 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы докладында булган тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3435-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 242. «Россия Федерациясендә инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме турында» 495392-5 номерлы федераль закон проектын карауны тизләтү тәкъдиме белән Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме турында» 495392-5 номерлы федераль закон проектын карауны тизләтү тәкъдиме белән Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге мөрәҗәгатен хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3436-IV ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2014 елның 20 мартындагы
3436-IV ДС номерлы карарына
кушымта

«Россия Федерациясендә инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме турында» 495392-5 номерлы федераль закон проектын карауны тизләтү тәкъдиме белән Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате

Хөрмәтле Сергей Евгеньевич!

Россия Федерациясе инновацияле үсеш юлын төп өстенлекләрнең берсе итеп билгеләде. Дәүләт, эшкуарларны товар продукциясен җитештерүгә фән һәм техника казанышларын кертүгә һәм производство чараларын яңартуга өндәп, инновация эшчәнлеген үстерү белән кызыксынып, үзендә бу мөнәсәбәтләрне турыдан-туры җайга салу мөмкинлекләренә ия түгел, чөнки мондый катнашу эшкуарлыкның бәйсез булу принципларына каршы килер иде. Теләгән нәтиҗәгә, беренчедән, инновация эшчәнлеге субъектларын икътисадый стимуллаштыру һәм аларга дәүләт ярдәме күрсәтү юлы белән һәм, икенчедән, җитештерүнең иске ысулларын куллanучы, күп чыгымнар сорый торган һәм аз нәтиҗәле технологияләр куллану, конкуренциядә көчсез продукция җитештерү белән шөгыльләнүче җитештерүчеләр өчен уңайсыз икътисадый шартлар тудыру юлы белән ирешеп була.

Ләкин Россиядә хәзерге вакытта бу планнарны тормышка ашыру өчен кирәкле хокукый база юк. Бары тик тиешле дәрәҗәдә хокукый нигез булганда гына инновацияләрне булдыру һәм аларны кертеп җибәрү мөмкин була, инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтелә ала. Хәзерге вакытта законнар системасындагы эшләнеп җитмәгән урыннар инновация икътисадына күчүне күпмедер дәрәҗәдә тоткарлыйлар.

Бүгенге көндә инновация эшчәнлеген җайга салуның төп нигезен «Фән һәм дәүләт фән-техника сәясәте турында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль закон тәшкил итә, аның 2 статьясына «инновация», «инновация проекты», «инновация инфраструктурасы», «инновация эшчәнлеге» төшенчәләренә кагылышлы үзгәрешләр кертелде. Кызганыч, федераль законнарда инновация эшчәнлеге субъектлары һәм объектлары билгеләнмәгән, аларга билгеләмә бирү инновацияләр белән эшләү һәм аларны кертү белән шөгыльләнүче субъектларның дәүләт ярдәме чаралары күрсәтелә торган төгәл даирәсен билгеләргә мөмкинлек биргән булыр иде.

Россия Федерациясе регионнарында инновация эшчәнлеге өлкәсендәге законнарга анализ ясау хокукый җайга салу эчтәлегендә һәм предметында бердәйлекнең булмавын күрсәтте. Законнарда, кагыйдә буларак, түбәндәгеләр күрсәтелә: законның җайга салу предметы, законның хокукый нигезләре, төп терминнар һәм төшенчәләр, инновация эшчәнлегенең асылы һәм төрләре, инновация эшчәнлеге субъектлары һәм объектлары. Шулай, 6 регионда фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлектә һәм, аерым алып, инновация эшчәнлегендә хокукый мөнәсәбәтләрне җайга сала торган нигез законнар кабул ителгән (Калуга, Новосибирск, Томск өлкәләре, Пермь һәм Красноярск крайлары, Башкортостан һәм Татарстан республикалары). Нәтиҗәдә региональ законнарда, хокукый җайга салу предметыннан чыгып, инновация эшчәнлегенең теге яисә бу аспектлары ассызыкланган, ә инновация эшчәнлеген җайга салуның кайбер мәсьәләләре җитәрлек дәрәҗәдә ачылмаган килеш кала бирә.

Югарыда бәян ителгәннәргә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Сезгә «Россия Федерациясендә инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме турында» 495392-5 номерлы федераль закон проектын карауны тизләтү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 243. «Сугыш балалары» статусын һәм гражданнарның күрсәтелгән категориясенә социаль ярдәм чараларын билгеләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатьләре турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Сугыш балалары» статусын һәм гражданнарның күрсәтелгән категориясенә социаль ярдәм чараларын билгеләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Мед-

ведевка һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатьләре текстларын кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге мөрәҗәгатьләрен хуплауны сорап Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына мөрәҗәгать итәргә.

4. Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына әлеге мөрәҗәгатьләрне хуплауны һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында «сугыш балалары» статусын федераль дәрәҗәдә билгеләү турындагы мәсьәләне карау инициативасы белән чыгуны сорап мөрәҗәгать итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3437-IV ДС

2014 елның 20 мартындагы
3437-IV ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
кушымта

## «Сугыш балалары» статусын һәм гражданнарның күрсәтелгән категориясенә социаль ярдәм чараларын билгеләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате

Хөрмәтле Дмитрий Анатольевич!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына балигъ булмаган яшьтә 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы авырлыкларыннан һәм мохтаҗлыгыннан сыналган, якыннарын һәм туганнарын югалтуны кичергән, ачлыкны һәм җимереклекне күргән,



җиңүне якынайту өчен тылда өлкәннәр белән беррәттән хезмәт иткән гражданнардан күпсанлы мөрәҗәгатьләр керә. Хәзерге вакытта аларның күбесе олы яшьтә булулары, сәламәтлекләрен югалту, ялгызлык аркасында өстәмә ярдәмгә мохтаҗ.

Федераль һәм региональ законнар белән әлеге категориядәге гражданнарның күбесенә инвалид, тыл хезмәтчәне, хезмәт ветераны буларак яки башка нигезләрдә социаль ярдәм чаралары күрсәтелсә дә, «сугыш балалары» арасыннан булганнар социаль яктан тиешенчә якланмаган булып кала бирә. Россия Федерациясенең кайбер субъектларында «сугыш балалары» статусы һәм социаль ярдәм чаралары булдыруга юнәлдерелгән норматив хокукый актлар кабул ителде. Шул ук вакытта регионнарда гражданнарны бу категориягә кертү тәртибе һәм шартлары, социаль ярдәм чараларының исемлеге һәм күләме төрле. Әлеге мәсьәләне регионнар төрле юллар белән хәл итәргә мәҗбүр, чөнки ул турыдан-туры Россия Федерациясе субъектының финанс мөмкинлекләренә бәйле.

Бу хәл Россия төбәкләренең авыр сугыш елларын узган һәм гадел рәвештә дәүләттән Россия Федерациясенең бөтен территориясендә бер үк төрле социаль ярдәм алуга дәгъва белдерә торган халкы арасында аңлашылмаучанлык тудыра.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары халыкның «сугыш балалары» арасыннан булган гражданнарны социаль яклау мәсьәләләрен хокукый җайга салу кирәклеге турындагы фикерен хуплый.

Әйтелгәннәрдән чыгып, шулай ук Бөек Ватан сугышында Җиңүнең киләчәктә 70 еллыгын бәйрәм итүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы «сугыш балалары» статусын һәм гражданнарның күрсәтелгән категориясенә социаль ярдәм чараларын билгеләү мәсьәләсен федераль дәрәҗәдә карауны сорап Россия Федерациясе Хөкүмәтенә мөрәҗәгать итә.

2014 елның 20 мартындагы
3437-IV ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
кушымта

«Сугыш балалары» статусын һәм гражданнарның күрсәтелгән категориясенә социаль ярдәм чараларын билгеләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате

Хөрмәтле Сергей Евгеньевич!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына балигъ булмаган яшьтә 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы авырлыкларыннан һәм мохтаҗлыгыннан сыналган, якыннарын һәм туганнарын югалтуны кичергән, ачлыкны һәм җимереклекне күргән, җиңүне якынайту өчен тылда өлкәннәр белән беррәттән хезмәт иткән гражданнардан күпсанлы мөрәҗәгатьләр керә. Хәзерге вакытта аларның күбесе олы яшьтә булулары, сәламәтлекләрен югалту, ялгызлык аркасында өстәмә ярдәмгә мохтаҗ.

Федераль һәм региональ законнар белән әлеге категориядәге гражданнарның күбесенә инвалид, тыл хезмәтчәне, хезмәт ветераны буларак яки башка нигезләрдә социаль ярдәм чаралары күрсәтелсә дә, «сугыш балалары» арасыннан булганнар социаль яктан тиешенчә якланмаган булып кала бирә. Россия Федерациясенең кайбер субъектларында «сугыш балалары» статусы һәм социаль ярдәм чаралары булдыруга юнәлдерелгән норматив хокукый актлар кабул ителде. Шул ук вакытта регионнарда гражданнарны бу категориягә кертү тәртибе һәм шартлары, социаль ярдәм чараларының исемлеге һәм күләме төрле. Әлеге мәсьәләне регионнар төрле юллар белән хәл итәргә мәҗбүр, чөнки ул турыдан-туры Россия Федерациясе субъектының финанс мөмкинлекләренә бәйле.

Бу хәл Россия төбәкләренең авыр сугыш елларын узган һәм гаделрәвештә дәүләттән Россия Федерациясенең бөтен территориясендә бер үк төрле социаль ярдәм алуга дәгъва белдерә торган халкы арасында аңлашылмаучанлык тудыра.



Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары халыкның «сугыш балалары» арасыннан булган гражданнарны социаль яклау мәсьәләләрен хокукый җайга салу кирәклеге турындагы фикерен хуплый.

Әйтелгәннәрдән чыгып, шулай ук Бөек Ватан сугышында Җиңүнең киләчәктә 70 еллыгын бәйрәм итүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы «сугыш балалары» статусын һәм гражданнарның күрсәтелгән категориясенә социаль ярдәм чараларын билгеләү мәсьәләсен федераль дәрәҗәдә карауны сорап Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына мөрәҗәгать итә.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 244. «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Ставрополь крае Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3438-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 245. «Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясына үзгәреш кертү турында» 407653-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясына үзгәреш кертү турында» 407653-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3439-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 246. «Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясына үзгәреш кертү турында» 400469-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясына үзгәреш кертү турында» 400469-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3440-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 247. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.30 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 449423-6 номерлы федераль закон проекты турында (статьяга яңа состав өстәү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.30 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 449423-6 номерлы федераль закон проектын (статьяга яңа состав өстәү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3441-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 248. «Административ хокук бозулар турындагы эшләрне караганда һәм суд утырышларында хәбәрдарлык принцибын тәэмин итүгә бәйле кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 440681-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турындагы эшләрне караганда һәм суд утырышларында хәбәрдарлык принцибын тәэмин итүгә бәйле кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 440681-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3442-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 249. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 439866-6 номерлы федераль закон проекты турында (урман кишәрлекләрен рөхсәтсез биләгән өчен җаваплылыкны көчәйтү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 439866-6 номерлы федераль закон проектын (урман кишәрлекләрен рөхсәтсез биләгән өчен җаваплылыкны көчәйтү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3443-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 250. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.



2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3444-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 251. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $14.1^2$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $14.1^2$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3445-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**252. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган махсус техник чаралар яисә фото һәм кино төшерү, видеоязма чаралары белән административ хокук бозуларны теркәү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасы турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган махсус техник чаралар яисә фото һәм кино төшерү, видеоязма чаралары белән административ хокук бозуларны теркәү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Ленинград өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3446-IV ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**253. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 430094-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү турындагы карарга шикаять белдерү мәсьәләсе буенча)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 430094-6 номерлы федераль закон проектын (муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү турындагы карарга шикаять белдерү мәсьәләсе буенча) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3447-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**254. «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзасы статусы һәм Дәүләт Думасы депутаты статусы турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзасы статусы һәм Дәүләт Думасы депутаты статусы турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» федераль закон

проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3448-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 255. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 32 һәм 33 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Красноярск крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 32 һәм 33 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Красноярск крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын (үзләренең гамәлләре (гамәл кылмавы) белән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы эшендә аны таркатуга китергән киртәләр тудырган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль сайлауларда катнашуына чикләүләр билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Красноярск крае Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3449-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 256. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3450-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 257. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе

Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаена җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3451-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 258. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 12 статьясына һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 12 статьясына һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаена җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3452-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 259. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3453-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 260. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 43.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 43.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Орен-

бург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3454-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 261. «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 416826-6 номерлы федераль закон проекты турында (Федераль закон белән җайга салына торган хокукый мөнәсәбәтләрнең аерым субъектларының вәкаләтләрен төгәлләштерү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 416826-6 номерлы федераль закон проектын (Федераль закон белән җайга салына торган хокукый мөнәсәбәтләрнең аерым субъектларының вәкаләтләрен төгәлләштерү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3455-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 262. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян сала торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль законның 11 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 264377-6 номерлы федераль закон проекты турында (балаларны тамаша чараларына керткән өчен контрольне тәэмин итү мәсьәләсе буенча)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян сала торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль законның 11 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 264377-6 номерлы федераль закон проектын (балаларны тамаша чараларына керткән өчен контрольне тәэмин итү мәсьәләсе буенча) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3456-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 263. «Вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерү турында» Федераль законның $4^2$ һәм $4^3$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 448436-6 номерлы федераль закон проекты турында (иминләштерелгән затларның иминләштерүчедән түләүсез юридик ярдәм алу хокукын тәэмин итү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерү турында» Федераль законның $4^2$ һәм $4^3$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»

448436-6 номерлы федераль закон проектын (иминләштерелгән затларның иминләштерүчедән түләүсез юридик ярдәм алу хокукын тәэмин итү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3457-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 264. «Һөнәр берлекләре, аларның хокуклары һәм эшчәнлек гарантияләре турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 441566-6 номерлы федераль закон проекты турында (һөнәр берлекләре органнары составында инвалидлар өчен квоталар билгеләү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Һөнәр берлекләре, аларның хокуклары һәм эшчәнлек гарантияләре турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 441566-6 номерлы федераль закон проектын (һөнәр берлекләре органнары составында инвалидлар өчен квоталар билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3458-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 265. «Ветераннар турында» Федераль законның $23^2$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 362186-6 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби гамәлләр инвалидларына һәм ветераннарына, һәлак (вафат) булган хәрби гамәлләр инвалидларының һәм ветераннарының гаилә әгъзаларына бирелә торган торакның гомуми мәйданы күләмен арттыру турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Ветераннар турында» Федераль законның $23^2$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 362186-6 номерлы федераль закон проектын (хәрби гамәлләр инвалидларына һәм ветераннарына, һәлак (вафат) булган хәрби гамәлләр инвалидларының һәм ветераннарының гаилә әгъзаларына бирелә торган торакның гомуми мәйданы күләмен арттыру турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3459-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 266. «Ветераннар турында» Федераль законның $23^2$ статьясына һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның $28^2$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Ветераннар турында» Федераль законның $23^2$ статьясына һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның $28^2$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында»

федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Ярославль өлкә Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3460-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 267. «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 428905-6 номерлы федераль закон проекты турында (сирәк очрый торган (орфан) авыруларны дәвалау өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 428905-6 номерлы федераль закон проектын (сирәк очрый торган (орфан) авыруларны дәвалау өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

г. Казань,
20 марта 2014 года
№ 3461-IV ГС



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 268. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 409030-6 номерлы федераль закон проекты турында (физик культура һәм спорт өлкәсендә кадрларны аттестацияләү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 409030-6 номерлы федераль закон проектын (физик культура һәм спорт өлкәсендә кадрларны аттестацияләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3462-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 269. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 411817-6 номерлы федераль закон проекты турында («балалар-яшүсмерләр спорты» төшенчәсен кертү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 411817-6 номерлы федераль закон проектын («балалар-яшүсмерләр спорты» төшенчәсен кертү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3463-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 270. «Россия Федерациясендә FIFA футбол буенча 2018 елгы дөнья чемпионатын, FIFA 2017 елгы Конфедерация кубогын әзерләү һәм үткәрү, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 453289-6 номерлы федераль закон проекты турында (күрсәтелгән Федераль законның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә FIFA футбол буенча 2018 елгы дөнья чемпионатын, FIFA 2017 елгы Конфедерация кубогын әзерләү һәм үткәрү, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 453289-6 номерлы федераль закон проектын (күрсәтелгән Федераль законның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3464-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 271. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» 442638-6 номерлы федераль закон проекты турында (1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон терминологиясен «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законда кулланыла торган терминнарга туры китерү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» 442638-6 номерлы федераль закон проектын (1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон терминологиясен «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законда кулланыла торган терминнарга туры китерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3465-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 272. «Россия Федерациясендә арбитраж судлар турында» Федераль конституциячел законга үзгәрешләр кертү хакында» 466627-6 номерлы федераль конституциячел закон проекты турында (Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмәләр турында «Россия Федерациясе Югары Суды һәм Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Россия Федерациясе Законы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә арбитраж судлар турында» Федераль конституциячел законга үзгәрешләр кертү хакында» 466627-6 номерлы федераль конституциячел закон проектын (Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмәләр турында «Россия Федерациясе Югары Суды һәм Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Россия Федерациясе Законы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3466-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 273. «Гомуми юрисдикция судларында һәм арбитраж судларда карала торган кайбер категориядәге эшләрнең ведомство буйсынуы үзгәрүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 466637-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Гомуми юрисдикция судларында һәм арбитраж судларда карала торган кайбер категориядәге эшләрнең ведомство буйсынуы үзгәрүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 466637-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 марты
№ 3467-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 274. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Калуга өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

